# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында" Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм турында" 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш) түбәндәге эчтәлекле өченче өлеш өстәргә:

"Әгәр граждан бер үк вакытта әлеге Закон һәм федераль закон яисә бүтән норматив хокукый акт буенча айлык акчалата түләүгә аны билгеләү нигезенә бәйсез рәвештә ("Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны социаль яклау турында" Россия Федерациясе Законы (1992 елның 18 июнендәге 3061-1 номерлы Россия Федерациясе Законы редакциясендә), "Семипалатинск полигонындагы атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар булган гражданнарга социаль гарантияләр турында" 2002 елның 10 гыйнварындагы 2-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә айлык акчалата түләү билгеләү очракларыннан гайре) хокуклы булса, гражданга, ул сайлап алганча, йә әлеге Закон, йә федераль закон яисә бүтән норматив хокукый акт буенча айлык акчалата бер түләү бирелә.".

**2 статья**

Әлеге Закон 2012 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 58-ТРЗ